**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИ**
**И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОЕ**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ**
**РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан шәһәре **БОЕРЫК**

09.10.2018 1010-п

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Күгеш торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Су кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү өчен кулланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибе турында» 2012 елның 29 февралендәге 177 номерлы карары нигезендә һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына 2018 елның 27 июнендәге ТАТ ЗЛД 01946 ВЭ лицензияне, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы, Кайбыч районнарындагы территориаль бүлегенең 26.03.2018 № 16.20.01.000.Т.000003.03.18 проектның дәүләт санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килү турында санитар-эпидемиологик бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук Зеленодольск районының «Нурлат ТКХ КҖП» ҖЧҖ тарафыннан тәкъдим ителгән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы, Күгеш торак пунктында эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы проекты нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Күгеш торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы проектын (алга таба – Проект) расларга.

2. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Күгеш торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы чикләрен билгеләргә.

3. 2 нче кушымта нигезендә әлеге су алу корылмасының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимын билгеләргә.

4. Проект күчермәсен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәге чараларны үткәрү турында тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш торак пунктында эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы чикләре, су алу җайланмасының санитар саклык зонасы чикләрендәге территорияләрдән хуҗалыкта файдалану кагыйдәләре һәм режимы турында халыкка хәбәр итүне оештыру турында;

территорияләр үсешенең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналарга бүлү схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә Проектны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
09.10.2018 №1010-п боерыгына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Күгеш пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы чикләре**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш торак пунктында карала торган «Нурлат ТКХ КҖП» МУП су алу корылмасы №1 (95) су алу скважинасын эксплуатацияли, ул Әрә елгасының (Зөя елгасының сул кушылдыгы) сул яр сөзәклегендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан.

№1 (95) су алу скважинасының географик координаталары: т.к. $55^{0}39'45{,}9''$, к.о. $48^{0}10'27{,}9''$.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык сууткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы

Сулы горизонтның яхшы якланган булуын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш торак пунктындагы №1 (95) су алу скважинасының санитар саклык зонасындагы беренче пояс чиге түбәндәгечә аралыкларда билгеләнә: төньяк-көнбатыш юнәлештә – скважина авызыннан 30 метр, төньяк-көнчыгыш – 30 метр, көньяк-көнчыгыш – 20 метр, көньяк-көнбатыш – 20 метр.

Санитар саклык зонасының II поясы

Әлеге скважинаның санитар саклык зонасындагы икенче поясның чикләре аның авызыннан 31 метрлы радиус белән билгеләнә.

Санитар саклык зонасының III поясы

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш торак пунктындагы №1 (95) су алу скважинасының санитар саклык зонасындагы өченче поясының радиусы 216 метрга тигез.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
09.10.2018 № 1010-п боерыгына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районындаКүгеш торак пунктында эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасында территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы**

1. Санитар саклык зоналарының беренче поясы

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үткәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар саклык зонасындагы беренче поястан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналарны бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик якланган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.